Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кибәч авыл җирлеге
Советының кырык сигезенче утырышы

**КАРАР**

2018 елның 13 декабре № 117

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кибәч авыл җирлеге
Советының «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кибәч авыл
җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр
кертү турында» карары проекты турында

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Кибәч авыл җирлеге уставын «Җирле үзидарә оештыруны камилләштерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 18 апрелендәге 83-ФЗ номерлы федераль законнарга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында «Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 6 октябрендәге 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кибәч авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 86, 87, 88 статьялары нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кибәч авыл җирлеге Советы карар кабул итте:**

1. Кушымта нигезендә «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кибәч авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кибәч авыл җирлеге Советы карары проектын беренче укылышта кабул итәргә.
2. Әлеге карарны Кибәч авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, шулай ук Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Кибәч авыл җирлеге башлыгы Р.Ә. Рәимов

Питрэч муниципаль районы Кибәч авыл җирлеге
Советының 2018 елның 13 декабрендәге 117
номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Питрэч муниципаль районы
Кибәч авыл җирлеге Советы утырышы

КАРАР

2019 ел №

«Татарстан Республикасы Питрэч муниципаль районы Кибәч авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»

Татарстан Республикасы Питрэч муниципаль районының Кибәч авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставын «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131- ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Питрэч муниципаль районы Кибәч авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 86, 87, 88 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Питрэч муниципаль районы Кибәч авыл җирлеге муниципаль, **Татарстан Республикасы Питрэч муниципаль районы Кибәч авыл җирлеге Советы карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кибәч авыл җирлеге Советының 2015 елның 15 июнендәге 18 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрэч муниципаль районы Кибәч авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.
3. Әлеге карарны Кибәч авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, шулай ук Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru).
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Питрэч муниципаль районы
Кибәч авыл җирлеге башлыгы Р.Ә. Рәимов

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ПЕСТРЕЧИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «КИБЯЧИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
СОВЕТ КИБЯЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1633000810

Кибәч авыл җирлеге
Советы карарына
кушымта № _
2019 ел.____________

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кибәч авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

1. «Җирлекләрнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә кертелмәгән мәсьәләләрне хәл итүгә Җирлек җирле үзидарә органнарының хокуклары» 6 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 16 пункт өстәргә:

"16) «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законы белән каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыру.».

2. «Гавами тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышу» 19 статьяның 3 өлешендәге 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) муниципаль берәмлек уставы проекты, шулай ук әлеге уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль норматив хокукый акт проекты, муниципаль берәмлек Уставына Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе яисә законнары нигезләмәләрен әлеге уставны әлеге норматив хокукый актларга туры китерү максатларында төгәл күрсәтү рәвешендә үзгәрешләр кертелә торган очраклардан тыш;».

3. 49 статьяның 2 өлешендә «Башкарма комитет вәкаләтләре» түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә: «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыра.

4. 71 статьяда «Муниципаль хокукый актларны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм үз көченә керү тәртибе»:

- 3 өлешне яңа редакциядә баян итәргә: «3. Кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар, гамәлгә куючы булып муниципаль берәмлек торган оешмаларның хокукый статусын билгели торган муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка игълан итү) үз көченә керә.

Муниципаль хокукый актны яисә җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне рәсми бастырып чыгару булып, аның тулы текстын тиешле муниципаль берәмлектә таратыла торган вакытлы матбугатта беренче бастырып чыгару санала.

Муниципаль хокукый актларны һәм килешүләрне рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен җирле үзидарә органнары шулай ук челтәр (сетевое) басмасыннан файдаланырга хокуклы. Рәсми челтәр басмасында муниципаль хокукый актның тулы тексты басылып чыккан (урнаштырган) очракта, басма басмада аңа күләмле график һәм таблица рәвешендә кушымталар китерелергә мөмкин.

Муниципаль хокукый актларны, җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләрне бастырып чыгару (халыкка игълан итү) тәртибе муниципаль берәмлек уставы белән билгеләнә һәм алар белән, муниципаль хокукый актлардан яки аларның федераль закон белән чикләнә торган белешмәләре булган аерым нигезләмәләрдән тыш, танышу мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.

Муниципаль хокукый актны бастырып чыгарганда (халыкка җиткергәндә) кабул ителә торган актның тулы һәм ышанычлы реквизитлары, шул исәптән графигы күрсәтелергә тиеш.»;

- 9 өлештә «Муниципаль хокукый актларны рәсми бастырып чыгару (халыкка игълан итү)» сүзеннән соң «һәм җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр» сүзләрен өстәргә.

5. «Җирлек Уставы проектын әзерләү, әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү тәртибе»: 86 статьяның 4 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Авыл җирлеге Уставы проекты, әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт проекты буенча аларны җирлек Советы утырышында карау алдыннан әлеге Устав нигезендә ачык тыңлаулар үткәрелә, Уставка үзгәрешләр бары тик җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне һәм аларны хәл итү вәкаләтләрен Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә яисә законнарына туры китерү максатларында гына кертелә торган очраклардан тыш.»